ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№_107_

П Р И К А З                                                                Б О Е Р Ы К

«_28_» __август,_ 2023_ ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составын раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 1 июлендәге 821 номерлы указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссияләр турында» 2010 елның 25 августындагы ПУ-569 номерлы указы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә (кушымтада бирелә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә (кушымтада бирелә) расларга.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 12.02.2016 № 53;

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2016 елның 12 февралендәге 53 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 19.12.2017 № 408;

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 02.03.2023 № 28.

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «28 « _август, _ 2023 ел, № _107_ боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиясен (алга таба – Комиссия) формалаштыру һәм аның эшчәнлек тәртибе билгеләнә.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Комиссиянең төп бурычы түбәндәгеләргә ярдәм итү тора:

а) Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмый калу яисә җайга салу турында чикләмәләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тәэмин итүдә, шулай ук алар тарафыннан «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән бурычларның үтәлешен (алга таба – хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу) тәэмин итүдә;

б) Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә (алга таба – ТР ДТИ) коррупцияне кисәтү чараларын гамәлгә ашыруда.

4. Комиссия ТР ДТИ Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын (алга таба – дәүләт хезмәте вазыйфалары) биләүче граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга бәйле мәсьәләләрне карый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләп куела һәм азат ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләреннән тыш).

ТР ДТИ Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләп куела һәм азат ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга бәйле мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында төзелгән хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе тарафыннан карала.

## II. Комиссия составы

5. Комиссия ТР ДТИ җитәкчесе тарафыннан ТР ДТИда дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары арасыннан билгеләп куела торган рәис, рәис урынбасары, Комиссия секретаре һәм Комиссиянең башка әгъзаларыннан тора. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмый торганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.

6. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

ТР ДТИ җитәкчесе урынбасары (Комиссия рәисе), кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы көрәш бүлеге җитәкчесе, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат (Комиссия секретаре), юридик бүлек җитәкчесе, ТР ДТИ башка структур бүлекчәләренең дәүләт хезмәткәрләре, ТР ДТИ җитәкчесе билгеләгән дәүләт хезмәткәрләре;

б) Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсеннән һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсеннән вәкил;

в) эшчәнлекләре дәүләт хезмәтенә бәйле булган фәнни оешмалардан, һөнәри белем бирү оешмаларыннан, югары белем бирүче мәгариф оешмаларыннан һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан вәкил (вәкилләр).

7. ТР ДТИ җитәкчесе түбәндәгеләрне Комиссия составына кертү турында карар кабул итә ала:

а) ТР ДТИ каршында оештырылган Иҗтимагый совет вәкилен;

б) ТР ДТИ оештырылган ветераннарның иҗтимагый оешмасы вәкилен;

в) билгеләнгән тәртиптә ТР ДТИ гамәлдә булган профсоюз оешмасы вәкилен.

8. Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктының «б» һәм «в» пунктчаларында һәм 7 пунктында күрсәтелгән затлар Комиссия составына билгеләнгән тәртиптә, ТР ДТИ җитәкчесе гарызнамәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәсе, фәнни оешмалар, һөнәри белем бирү оешмалары, югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары белән, ТР ДТИ каршында төзелгән иҗтимагый совет, ТР ДТИ оештырылган ветераннарның иҗтимагый оешмасы, билгеләнгән тәртиптә ТР ДТИ эшли торган профсоюз оешмасы белән килештереп, министр гаризасы нигезендә кертелә. Килештерү гариза алынганнан соң 10 көн эчендә башкарыла.

9. ТР ДТИ дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләмәгән Комиссия әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми исәбеннән кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

10. Комиссия составы Комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеген калдырмаслык итеп төзелә.

11. Комиссия утырышларында киңәшләшү тавышына хокуклы булган түбәндәгеләр катнаша:

а) үзенә карата хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу мәсьәләсе Комиссиядә карала торган дәүләт хезмәткәренең турыдан-туры җитәкчесе һәм Комиссия рәисе билгели торган, ТР ДТИ дәүләт хезмәте вазыйфаларын, үзенә карата Комиссиядә әлеге мәсьәлә каралачак дәүләт хезмәткәре биләгән аналогик вазыйфаларны биләүче ике дәүләт хезмәткәре;

б) ТР ДТИ дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче башка дәүләт хезмәткәрләре; дәүләт хезмәте мәсьәләләре һәм Комиссиядә карала торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә ала торган белгечләр; башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан вазыйфаи затлар; мәнфәгатьле оешмаларның вәкилләре; үзенә карата хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу мәсьәләсе комиссиядә карала торган дәүләт хезмәткәренең вәкиле, – һәр конкрет очракта үзенә карата Комиссиядә әлеге мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең яисә Комиссиядәге теләсә кайсы әгъзаның үтенеч язуы нигезендә Комиссия утырышы көненә кадәр кимендә өч көн калганчы комиссия рәисе тарафыннан кабул ителә торган карар буенча.

12. Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, Комиссия утырышы тулы хокуклы булып санала. ТР ДТИ дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче Комиссия әгъзалары катнашында гына утырышлар уздыру рөхсәт ителми.

14. Комиссия әгъзасында Комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә ала торган турыдан-туры яки читләтеп шәхси кызыксынучанлык барлыкка килгән очракта, ул бу хакта утырыш башланганчы хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта Комиссиянең тиешле әгъзасы әлеге мәсьәләне карауда катнашмый.

## III. Комиссиянең эш тәртибе

14. Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

а) дәүләт хезмәткәрләре тапшырган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булу-булмавына һәм дәүләт хезмәткәренең хезмәттә үз-үзеңне тотуга карата таләпләрнең үтәлүенә карата Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә уздырылган тикшерү йомгаклары буенча ТР ДТИ җитәкчесенең түбәндәгеләрне таныклаучы тикшерү материалларын тапшыруы:

дәүләт хезмәткәрләренең Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарның керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында нигезләмәдә каралган белешмәләрне төгәл яисә тулы итеп тапшырмавы турында;

дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве турында;

б) ТР ДТИ норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка кергән түбәндәгеләр:

әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләр аның вазыйфаи (хезмәт) бурычларына караган булса, дәүләт хезмәтеннән киткән көннән соң ике ел узганчы ТР ДТИ Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфасын биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъլык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга бурычлы булган ТР ДТИ Татарстан Республикасы дәүләт хезмәте вазыйфалары исемлегенә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның коммерциячел яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә яисә граждани-хокукый килешү шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруга ризалык бирү турында мөрәҗәгать итүе;

дәүләт хезмәткәренең объектив сәбәпләр аркасында үзенең хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру мөмкинлеге булмавы турында гаризасы;

территориясендәге чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булган, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләре сакланган һәм (яисә) чит ил финанс кораллары булган чит ил дәүләтендә компетентлы органнар тарафыннан әлеге чит ил дәүләте законнары нигезендә салынган арестка, эш итүне тыюга бәйле рәвештә яки үз ихтыярына яки хатынының (иренең) һәм балигъլык яшенә җитмәгән балаларының ихтыярына бәйле булмаган башка төрле шартлар аркасында дәүләт хезмәткәреннән – «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен үтәү мөмкинлеге булмавы турында гариза;

дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында белдерүе;

в) ТР ДТИ җитәкчесенең яисә Комиссиядәге теләсә кайсы әгъзаның дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәвен тәэмин итүгә яисә ТР ДТИ коррупцияне кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыруга кагылышлы йогынты акты;

г) ТР ДТИ җитәкчесенең дәүләт хезмәткәре тарафыннан «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм бүтән затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешендә каралган белешмәләрнең төгәл яисә

тулы булмаган рәвештә тапшырылуы турында таныклаучы тикшерү материалларын тапшыруы;

д) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясының 4 өлеше һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 64.1 статьясы нигезендә ТР ДТИ коммерциячел яисә коммерциясез оешмадан килгән, ТР ДТИ дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин белән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яки граждани-хокукый шартнамә төзү турында белдерү, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның ТР ДТИ вазыйфаны биләгән вакытта үтәгән вазыйфаи (хезмәт) бурычларына караган булса, күрсәтелгән гражданинга Комиссия тарафыннан элегрәк әлеге оешма белән хезмәт яисә граждани-хокукый мөнәсәбәтләргә керүдән баш тарту яисә мондый гражданинга аның коммерциячел оешмада яисә коммерциясез оешмада вазыйфа биләвенә яки аның граждани-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруына ризалык бирү турында мәсьәләнең Комиссиядә каралмаган булуы шарты белән.

15. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турында хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр үткәрми.

15.1. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать ТР ДТИ дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин тарафыннан ТР ДТИ  коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи затына бирелә. Мөрәҗәгатьтә түбәндәгеләр күрсәтелә: гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның туган датасы, яшәгән урыны буенча адресы, дәүләт хезмәтеннән киткән көнгә кадәр ике ел эчендә биләгән вазыйфалары, коммерциячел яки коммерциясез оешманың аталышы, урнашкан урыны, эшчәнлегенең холкы, дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән вакытта гражданин тарафыннан башкарыла торган вазыйфаи (хезмәт) бурычлар, коммерциячел яки коммерциясез оешмага карата дәүләт идарәсе буенча функцияләр, шартнамә төре (хезмәт яисә граждани-хокукый), аның күздә тотылган гамәлдә булу чоры, шартнамә буенча эшләрне башкарган (хезмәтләрне күрсәткән) өчен түләү суммасы. Коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи зат мөрәҗәгатьне карый, аның нәтиҗәләре буенча «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча мотивацияле бәяләмә әзерләнә.

15.2. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать дәүләт хезмәтеннән китәргә планлаштыручы дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылырга мөмкин һәм әлеге Нигезләмәгә туры китереп, Комиссия тарафыннан каралырга тиеш.

15.3. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәр коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан карала, ул Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге

273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы таләпләрен үтәве турында нигезләнгән бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра.

15.4. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта күрсәтелгән хәбәрләмә коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы булган вазыйфаи заты тарафыннан карала, ул хәбәрләмәне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра.

15.5. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында аталган мөрәҗәгатьне яисә әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «д» пунктчасында аталган белдерүләрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмәне әзерләгәндә коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы зат мөрәҗәгатьне яисә белдерүне тапшырган дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә уздыру, аннан язмача аңлатмалар алу хокукына ия, ә ТР ДТИ җитәкчесе яисә аның махсус шуңа вәкаләтле урынбасары билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм мәнфәгатьле оешмаларга гарызнамәләр җибәрә, коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдалана ала, шул исәптән гарызнамәләрне җибәрү өчен дә. Мөрәҗәгать яисә белдерү, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки белдерү килгән көннән соң җиде эш көне эчендә Комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яисә белдерү, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки белдерү килгән көннән соң 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артыгракка түгел.

15.6. Әлеге Нигезләмәнең 15.1, 15.3 һәм 15.4 пунктларында каралган дәлилле бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрләмәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне яисә хәбәрләмәләрне беренчел карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 22, 23.3, 24.1 пунктлары нигезендә карарларның берсен яисә башка төрле карарны кабул итү өчен киңәшләр.

16. Комиссия рәисе әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә Комиссия утырышын үткәрү өчен нигезләрне үз эченә алган мәгълүмат кергәндә:

а) 10 көнлек чорда Комиссия утырышы датасын билгели. Бу вакытта Комиссия утырышы датасы, әлеге Нигезләмәнең 16.1 һәм 16.2 пунктларында каралган очраклардан тыш, күрсәтелгән мәгълүмат килгән көннән соң 20 көнгә саңга калып билгеләнә алмый;

б) үзенә карата Комиссиядә хезмәт тәртибенә карата таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең, аның вәкиленең, Комиссия әгъзаларының һәм

Комиссия утырышында катнашучы башка затларның коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка килгән мәгълүмат белән, аны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруны оештыра;

в) әлеге Нигезләмәнең 11 пунктының «б» пунктчасында аталган затларны Комиссия утырышына чакыру турында үтенеч язуларын карый, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүдән баш тарту турында) һәм утырыш барышында өстәмә материалларны карау турында (караудан баш тарту турында) карар кабул итә.

16.1. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасындагы өченче һәм дүртенче абзацларда күрсәтелгән гаризаларны карау буенча Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән чор узган көннән соң бер ай узганчы уздырыла.

16.2. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «д» пунктчасында күрсәтелгән белдерү, кагыйдә буларак, Комиссиянең чираттагы (планга кертелгән) утырышында карала.

17. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, үзенә карата хезмәттә үз-үзеңне тотуга карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлеше турында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәре яисә ТР ДТИ дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин катнашында карала. Дәүләт хезмәткәре яисә гражданин Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләве турында әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасына ярашлы рәвештә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә белдерүдә күрсәтә.

17.1. Комиссия утырышлары дәүләт хезмәткәре яки гражданин булмаган очракта үткәрелергә мөмкин:

әгәр әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә белдерүдә дәүләт хезмәткәренең яисә гражданинның Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләве турында күрсәтелмәсә;

б) әгәр Комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләгән һәм аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешенчә хәбәр ителгән дәүләт хезмәткәре яки гражданин Комиссия утырышына килмәсә.

18. Комиссия утырышында дәүләт хезмәткәренең яисә ТР ДТИ дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинның (алар ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңлана, әлеге утырышка кертелгән мәсьәләләрнең асылы буенча материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

19. Комиссия әгъзалары һәм аның утырышында катнашкан затлар Комиссия эше барышында үзләренә билгеле булган мәгълүматларны игълан итәргә хокуклы түгел.

20. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданинның керемнәре турында,

мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыруы турында нигезләмәгә туры китереп дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын билгеләргә;

б) әлеге пунктның «а» пунктчасында аталган Нигезләмәгә туры китереп дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм (яки) тулы булмавын билгеләргә. Бу очракта Комиссия дәүләт органы җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.

21. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «а» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә тотуга карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәгәнлеген билгеләргә;

б) дәүләт хезмәткәренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәмәгәнлеген билгеләргә. Бу очракта Комиссия ТР ДТИ җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәүнең ярамаганлыгы турында күрсәтергә яисә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга киңәш итә.

22. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) гражданинга коммерциячел яисә коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә яки граждани-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруга ризалык бирергә, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфа (хезмәт) бурычларына керә торган булса;

б) гражданинга коммерциячел яисә коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә яки граждани-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруга ризалык бирмәскә, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфа (хезмәт) бурычларына керә торган булса, һәм мондый карарны нигезләргә.

23. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең үзенең хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмавының сәбәбе объектив һәм хөрмәткә лаеклы дип танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең үзенең хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмавының сәбәбе объектив һәм

хөрмәткә лаеклы түгел дип танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә күрсәтелгән белешмәләрне тапшыру буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәренең хатынының (иренең) һәм балигъылык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмавының сәбәбе объектив булмавын һәм күрсәтелгән белешмәләрне тапшырудан читләшү ысулы булып торуын танырга. Бу очракта Комиссия ТР ДТИ җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.

23.1. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «г» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм бүтән затларның керемнәре чыгымнарына туры килүен тикшереп тору турында» федераль законның 3 статьясының 1 өлешенә ярашлы рәвештә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм тулы булуын танырга;

б) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның керемнәре чыгымнарына туры килүен тикшереп тору турында» федераль законның 3 статьясының 1 өлешенә ярашлы рәвештә дәүләт хезмәткәре тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең төгәл һәм (яки) тулы булмавын танырга. Бу очракта Комиссия ТР ДТИ җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын кулланырга һәм (яки) чыгымнарны контрольдә тоту нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки) башка дәүләт органнарына аларның компетенциясенә ярашлы рәвештә җибәрергә тәкъдим итә.

23.2. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» федераль закон таләпләрен үтәүгә каршы килә торган шартларның объектив һәм хөрмәткә лаек булуын танырга;

б) «Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, нал белән акча чаралары һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс коралларына ия булуны һәм файдалануны тыю турында» федераль закон таләпләрен үтәүгә каршы килә торган шартларның объектив һәм хөрмәткә лаек булмавын танырга; Бу очракта Комиссия ТР ДТИ җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.

23.3. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы булмавын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта Комиссия дәүләт хезмәткәренә һәм (яисә) ТР ДТИ җитәкчесенә мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча яки аның барлыкка килүенә юл куймау буенча чаралар күрергә киңәш итә;

в) дәүләт хезмәткәре мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән дип танырга. Бу очракта Комиссия ТР ДТИ җитәкчесенә дәүләт хезмәткәренә карата конкрет җаваплылык чарасын күрергә киңәш итә.

24. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «а», «б», «г» һәм «д» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча, һәм нигезләр булган очракта, комиссия әлеге Нигезләмәнең 20 - 23, 23.1 - 23.3 һәм 24.1 пунктларында каралганнан башкачарак карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итүнең нигезләре һәм мотивлары Комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.

24.1. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «д» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия ТР ДТИ дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән гражданинга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) аңа коммерциячел яисә коммерциясез оешмада вазыйфа биләүгә яки граждани-хокукый шартнамә шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада эшләр башкаруга ризалык бирергә, әгәр әлеге оешманың дәүләт идарәсе буенча аерым функцияләре аның вазыйфа (хезмәт) бурычларына керә торган булса;

б) аның хезмәт шартнамәсе шартларында коммерциячел яки коммерциясез оешмада вазыйфа биләвенең һәм (яки) коммерциячел һәм коммерциясез оешмада эшләр башкаруының (хезмәтләр күрсәтүенең) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законның 12 статьясы таләпләрен бозуын билгеләргә. Бу очракта Комиссия ТР ДТИ җитәкчесенә күрсәтелгән хәлләр турында прокуратура органнарына һәм хәбәр җиткергән оешмага мәгълүмат ирештерергә киңәш итә.

25. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «в» пунктчасында каралган мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия тиешле карар кабул итә.

26. Комиссия карарларын үтәү өчен ТР ДТИ норматив хокукый актлары проектлары, ТР ДТИ җитәкчесе карарлары яисә күрсәтмәләре әзерләнергә мөмкин, алар билгеләнгән тәртиптә ТР ДТИ җитәкчесе каравына тапшырыла.

27. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Комиссия карарлары яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр Комиссия башка карар кабул итмәсә) Комиссия әгъзаларының утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

28. Комиссия карарлары аның утырышында катнашкан Комиссия әгъзалары имзалаган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасындагы икенче абзацта каралган мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карардан тыш, Комиссия карарлары ТР ДТИ җитәкчесе өчен тәкъдим итү рәвешендә була. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасындагы икенче абзацта күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителә торган карар мәҗбүри булып тора.

29. Комиссия утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Комиссия утырышының датасы, утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының фамилияләре, исемнәре, ата исемнәре (булган очракта);

б) үзенә карата хезмәттә үз-үзеңне тотуга карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләр үтәлеше турында мәсьәлә карала торган дәүләт хезмәткәренең фамилиясен, исемен, ата исемен (булган очракта) күрсәтеп, Комиссия утырышында карала торган һәр мәсьәләнең тәгъбирләнеше;

в) дәүләт хезмәткәренә карата белдерелә торган дәгъвалар, аларга нигез булган материаллар;

г) дәүләт хезмәткәренең һәм башка затларның белдерелә торган дәгъваларның асылы буенча аңлатмаларының эчтәлеге;

д) утырышта катнашкан затларның фамилияләре, исемнәре, ата исемнәре (булган очракта) һәм аларның чыгышларының кыскача бәян ителеше;

е) Комиссия утырышын уздыру өчен нигезне үз эченә алучы мәгълүмат чыганагы, мәгълүматның ТР ДТИ килгән датасы;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итү нигезе.

30. Комиссия карары белән риза булмаган Комиссия әгъзасы үз фикерен язмача формада бәян итәргә хокуклы, ул Комиссия утырышы беркетмәсенә зарури тәртиптә кушып куелырга һәм дәүләт хезмәткәре аның белән танышып чыгарга тиеш.

31. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе утырыш көне узганнан соң 7 көнлек чорда – ТР ДТИ башлыгына, тулысынча яки аннан өземтәләр рәвешендә – дәүләт хезмәткәренә, шулай ук Комиссия карары нигезендә бүтән мәнфәгатьле затларга җибәрелә.

32. ТР ДТИ җитәкчесе Комиссия утырышы беркетмәсен карарга бурычлы һәм үз компетенциясе кысаларында, дәүләт хезмәткәренә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану турында, шулай ук коррупциягә каршы торуны оештыруның бүтән мәсьәләләре буенча карар кабул иткәндә анда булган киңәшләрне исәпкә алырга хокуклы. Комиссия тәкъдимнәрен карау һәм кабул ителгән карар турында ТР ДТИ җитәкчесе Комиссиягә Комиссия утырышы беркетмәсе кергән көннән алып бер ай эчендә язма рәвештә хәбәр итә. ТР ДТИ җитәкчесе карары Комиссиянең якынлашып килүче утырышында игълан ителә һәм фикер алышусыз кабул ителә.

33. Комиссия тарафыннан дәүләт хезмәткәренең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар бозылу билгеләре билгеләнгән очракта, бу хакта мәгълүмат, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын дәүләт хезмәткәренә карата куллану мәсьәләсен хәл итү өчен ТР ДТИ җитәкчесенә тапшырыла.

34. Комиссия дәүләт хезмәткәренең административ хокук бозу билгеләрен яисә җинаять составын үз эченә ала торган гамәл кылуы фактын (гамәл кылмау фактын) ачыклаган очракта, Комиссия рәисе күрсәтелгән гамәлнең кылынуы (гамәл кылынмавы) турында мәгълүматны һәм әлеге фактны раслаучы документларны 3

көнлек чорда, ә зарурлык булганда – кичекмәстән, хокук куллану органнарына тапшырырга тиеш.

35. Комиссия утырышы беркетмәсенең күчермәсе яисә аннан алынган өземтә үзенә карата хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең һәм (яисә) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу турында таләпләрнең үтәлүе турында мәсьәлә каралган дәүләт хезмәткәренең шәхси эшенә кушып куела.

35.1. Комиссия секретаренең имзасы һәм ТР ДТИ мөһере белән расланган Комиссия карарыннан өземтә ТР ДТИ дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән, үзенә карата әлеге Нигезләмәнең 14 пунктының «б» пунктчасындагы икенче абзацта күрсәтелгән мәсьәлә каралган гражданинга кул куйдыртып тапшырыла яки аның тарафыннан мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән адрес буенча комиссиянең тиешле утырышы уздырылган көннән соң бер эш көне узганчы, белдерүле заказлы хат итеп җибәрелә.

36. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техника ягыннан һәм документлар белән тәэмин итү, шулай ук Комиссия әгъзаларына утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында, аның датасы, вакыты һәм уздырылу урыны турында мәгълүмат җиткерү, Комиссия әгъзаларын комиссия утырышында сөйләшү өчен тапшырыла торган материаллар белән таныштыру коррупциячел һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенең _23.08.2023_____ № _107_ боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Саттаров Вәгыйз Сөләйман улы | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасының Баш дәүләт торак инспекторы урынбасары – Хокук идарәсе җитәкчесе, Комиссия рәисе; |
| Хәкимова Гүзәл Риф кызы | кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы тору бүлегенең әйдәп баручы консультанты, Комиссия секретаре; |
| Воронская Наталья Николаевна | хокук идарәсенең юридик бүлеге җитәкчесе, Комиссия әгъзасы; |
| Никитина Инна Николаевна | кадрлар сәясәте һәм коррупциягә каршы тору бүлеге җитәкчесе, Комиссия әгъзасы; |
| Лохотской Александр Валерьевич | Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе вәкиле; |

**Бәйсез эксперт (килешү буенча):**

| | |
|---|---|
| Волкова Наталья Васильевна | Казан (Идел буе) федераль университетының Идарә, икътисад һәм финанслар институты доценты; |
| Фомина Татьяна Владимировна | Казан (Идел буе) федераль университетының Идарә, икътисад һәм финанслар институтының укыту-методика эшләре буенча 1 нче категорияле белгече; |

**Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе иҗтимагый советы вәкиле (килешү буенча):**

| | |
|---|---|
| Застела Михаил Юрьевич | «ТР ТКХ өлкәсендә иҗтимагый контроль төбәк үзәге» НП җитәкчесе; |
| Насрыев Рафаэль Мөнир улы | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе пенсионеры. |